КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 ноябрь г.Казань № 892

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 7 июнь, 438 нче; 2010 ел, 24 август, 676 нчы; 2010 ел, 22 декабрь, 1094 нче; 2011 ел, 25 гыйнвар, 41 нче; 2012 ел, 24 октябрь, 901 нче; 2013 ел, 28 март, 211 нче; 2016 ел, 26 август, 594 нче; 2017 ел, 13 июль, 492 нче; 2017 ел, 24 август, 597 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибендә:

2 нче пунктның икенче абзацында «җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасы территориясендә җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең» сүзләрен «җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне

раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән билгеләнгән Тәртиптә бирелә торган балага айлык пособие алучы булган гаиләләрнең (алга таба – җан башына исәпләнгән уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең)» сүзләренә алыштырырга;

9 нчы пунктның өченче абзацында «җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына яшәү минимумының билгеләнгән күләменнән кимрәк булган гаиләләрнең» сүзләрен «җан башына исәпләнгән уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымта исемендә «җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балаларны» сүзләрен «җан башына исәпләнгән уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балаларын» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү кысаларында Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы арасында мәгълүмат алмашу тәртибендә:

2 нче пунктта:

беренче абзацта «керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән кимрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балаларның» сүзләрен «җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә торган балага айлык пособие алучы булган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балаларын (алга таба – җан башына исәпләнгән уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балалары)» сүзләренә алыштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк регистры сегментын тапшыру, вәкаләтле хезмәткәрнең электрон имзасы куелып, саклана торган ысул белән DBF-файл рәвешендә гамәлгә ашырыла.»;

3 нче пунктта:

беренче абзацта «керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән кимрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар турында» сүзләрен «җан башына исәпләнгән уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балалары турында» сүзләренә алыштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җан башына исәпләнгән уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган һәм тулы кыйммәтле туклану алган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балалары турында мәгълүмат тапшыру, вәкаләтле хезмәткәрнең электрон имзасы куелып, саклана торган ысул белән DBF-файл рәвешендә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада:

исемендә «керемнәре яшәү минимумыннан түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балаларның» сүзләрен «җан башына исәпләнгән уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балаларының» сүзләренә алыштырырга;

беренче абзацта «керемнәре яшәү минимумыннан түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балаларның» сүзләрен «җан башына исәпләнгән уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балаларының» сүзләренә алыштырырга;

искәрмәдә «керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче балаларның» сүзләрен «җан башына исәпләнгән уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балаларының» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтаның искәрмәсендә «керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче балаларның» сүзләрен «җан башына исәпләнгән уртача кереме яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балаларының» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин